СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » февраль 2022 ел** **№ 128**

**Гражданнар тарафыннан капиталь корылмалар булмаган гаражлар төзү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү тәртибен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36-1 статьясының 2 пункты, «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокукларын сатып алуга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Гражданнар тарафыннан капиталь корылмалар булмаган гаражлар төзү өчен Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 6 декабрендәге 1170 номерлы карары, «Җир өчен аренда түләве турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1.Гражданнар тарафыннан капиталь корылма булмаган гаражлар төзү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
28.02.2022 ел, №128
карарына кушымта

**Гражданнар тарафыннан капиталь корылмалар булмаган гаражлар төзү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы милкендәге җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен, гражданнарның капиталь корылма булмаган гаражлар (алга таба - гаражлар астындагы җир кишәрлекләре) төзү өчен түләү күләмен билгеләү кагыйдәләрен билгели.

2. Гаражлар астындагы җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен еллык түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

РПл = Су х S х Ст х Кт,

биредә:

РПл - түләү күләме (сум);

Су - аның территориясендә «Транспорт» сегменты өчен расланган гараж урнашкан җир кишәрлеге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы буенча җирләрнең һәм җир кишәрлекләренең уртача кадастр бәясе

-------------------------------

<*> сегмент Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2017 елның 12 маендагы 226 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт кадастр бәяләве турындагы методик күрсәтмәләрнең «Күчемсез милек объектларын сегментацияләү» дигән 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән.

S -гаражларны урнаштыру схемасы нигезендә гараж астындагы җир кишәрлегенең файдаланыла торган мәйданы (кв.м);

Ст - «Җир өчен аренда түләве турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары белән расланган дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки автостоянкалар һәм гаражлар урнаштыру өчен арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве күләмен исәпләү өчен кулланыла торган коэффициент;

Кт - гараж астындагы җир кишәрлегенең урнашу урынын характерлаучы

коэффициент, ул территориясендә гаражлар урнашкан җир кишәрлеге булган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

Территориясендә гараж астындагы җир кишәрлеге булган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан җир кишәрлекләренең гаражлар урнашу урынын характерлый торган коэффициенты билгеләнмәгән очракта, 1 коэффициенты кулланыла.

3. Гараж төзү өчен җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалану турында шартнамә төзегәндә, Арча муниципаль районының законнар нигезендә муниципаль җир кишәрлеге белән эш итүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы (алга таба - вәкаләтле орган) мондый килешүдә гараж астындагы җир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләү үзгәрү очракларын һәм вакытын күздә тота.

Шул ук вакытта түләү, гараж төзү турында шартнамә төзелгәннән соң ел саен, әмма бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта, вәкаләтле орган тарафыннан инфляция дәрәҗәсе күләменә беръяклы тәртиптә үзгәрә, ул чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль законда билгеләнгән инфляция дәрәҗәсе күләменә, күрсәтелгән аренда шартнамәсе төзелгән елдан башлап чираттагы финанс елы башына ел саен кулланыла.

«Җир өчен аренда түләве турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 декабрендәге 1159 номерлы карары, «Транспорт» сегменты өчен Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2017 елның 12 маендагы 226 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт бәяләмәсе турындагы методик күрсәтмәләрнең «Куллану төрләрен исәпләү кодларын күрсәтеп, күчемсез милек объектларын сегментацияләү» дигән 1 нче кушымтасы нигезендә, территориясендә гараж астындагы җир кишәрлегенең уртача кадастр бәясе үзгәрүгә бәйле рәвештә түләү күләме үзгәргән елда түләү күләмен инфляция дәрәҗәсенә индексацияләү башкарылмый.